ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.10.2025 г.Мензелинск № 362

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 12.03.2015 № 237 "Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, милекләре һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны, шулай ук Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, милекләре һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны тәкъдим итү турында Нигезләмәне раслау турында" карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең 10.07.2023 № 286-ФЗ «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законының 13 статьясы 4 пункты, Россия Федерациясенең 01.04.2022 № 90-ФЗ «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законының 5 статьясы 1 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2015 елның 12 мартындагы 237 номерлы «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетында муниципаль хезмәт урыннарына дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, милекләре һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, милекләре һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турында Нигезләмәне раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 16 пунктның 2 абзацында «яки аларның тулы булмаган яки дөрес булмаган мәгълүматлар бирүе» сүзләрен «үз чыгымнары турында мәгълүматлар, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш, алдан ук тулы булмаган мәгълүматлар бирү, яки алдан ук дөрес булмаган мәгълүматлар бирү» сүзләре белән, «үзләренең ир (хатын) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүматларны бирмәү яки алдан ук тулы булмаган яки дөрес булмаган мәгълүматлар бирү» сүзләрен

«яки үзләренең ир (хатын) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүматларны бирмәү, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш, алдан ук тулы булмаган мәгълүматлар бирү, яки үзләренең ир (хатын) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында алдан ук дөрес булмаган мәгълүматлар бирү» сүзләре белән алыштырырга;

1.2. 6 пунктның в подпунктында «, акцияләр» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Д. А. Чухланцев